**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**РОЖДЕСТВЕНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

422631 Дятлово авылы,
Яшьлек урамы, 1 нчы йорт,
тел: 4-74-98

**СОВЕТ РОЖДЕСТВЕНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ЛАИШЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422631 д.Дятлово,
ул. Юности, д.1
тел: 4-74-98

---

**2020 елның 16 апреле** **51 номер**

# КАРАР

**2020 елда Рождествено авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турындагы хисап буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2014 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм Рождествено авыл җирлеге Советы Уставының 19 статьясы нигезендә, Рождествено авыл җирлегендә яшәүчеләрнең Рождествено авыл җирлеге Советы карарлары проектлары буенча фикер алышуда катнашу хокукларын гамәлгә ашыру максатларында, Рождествено авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елда Рождествено авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап буенча халык тыңлауларын 2021 елның «23» апреленә 14.00 сәгатьтә Рождествено мәдәният йорты бинасында билгеләргә.
2. 2020 елда Рождествено авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турындагы хисап буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне язма рәвештә, «22» апрельгә кадәр, түбәндәге адрес буенча җибәрергә: .Дятлово авылы, Яшьлек ур.,1 йорт яисә факс буенча 8843-78-4-74-98.
3. Җирлекнең Башкарма комитетына 2020 елда Рождествено авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турындагы хисап буенча гражданнарның гавами тыңлауларын үткәрүне, тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.
4.Әлеге карарны Рождествено авыл җирлеге бюджетының 2020 елда үтәлеше турында хисап белән Дятлово авылы, Яшьлек ур., 6а һәм Рождествено авылы, Үзәк ур., 45а.адресы буенча урнашкан мәгълүмати стендларда игълан итәргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Рождествено**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **С.М. Гуцу**